РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
БЕССОНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БЕССОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 51-2-18, факс 51-2-18

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 .10. 2025** **№2**

**2026 елда гражданнарга үзара салым кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Бессоновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2025 елның 12 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Югары Тархан торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча урнашкан Югары Тархан авыл мәдәният йорты бинасында билгеләргә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Югары Тархан авылы, Ленин урамы, 21 йорт.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлегенең Югары Тархан торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, күпбалалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 2026 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр), ирекледәр) һәм аларның гаилә әгъзалары (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар) һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (смета нигезендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау: вак таш, төзелеш комы сатып алу, Югары Тархан торак

пунктындагы Ленин, Николаев урамнарындагы эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен ташу, салу, түләү);

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм Югары Тархан торак пунктына электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлауны?».

» КАРШЫ «РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бессоновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ю. А. Врясов**